ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Татарстан Республикасы Гаилә кодексына
үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 25 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Гаилә кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 12 (II өлеш); 2011, № 9 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш); 2013, № 5, № 7; 2014, № 4, № 6 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 74 статьяның 3 өлешендә “Россия Федерациясе Саклык банкы бүлегендә бала исеменә ачылган счетка” сүзләрен “, күрсәтелгән акчалар, аларның суммасына капиталлаштырылган (исәпләнгән) процентларны да кертеп, Россия Федерациясе банкларында физик затлар кертемнәренең мәҗбүри иминият системасында иминләштерелгән һәм бер банк счетындагы яисә счетларындагы акчаларның җыелма күләме “Россия Федерациясе банкларында физик затларның кертемнәрен иминләштерү турында” 2003 елның 23 декабрендәге 177-ФЗ номерлы Федераль законда кертемнәр буенча каралган каплау күләменнән артмаса, банкта яисә банкларда бала исеменә ачылган счетка яисә счетларга” сүзләренә алмаштырырга;

2) 116 статьяның 1 өлешендә:
а) 9 пунктта “иҗтимагый иминлеккә” сүзләреннән соң “, тынычлыкка һәм кешелек иминлегенә” сүзләрен өстәргә;
б) 10 пунктта “иҗтимагый иминлеккә” сүзләреннән соң “, тынычлыкка һәм кешелек иминлегенә” сүзләрен өстәргә;

3) 134 статьяның 1 өлешендәге 2 пунктында “иҗтимагый иминлеккә” сүзләреннән соң “, тынычлыкка һәм кешелек иминлегенә” сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2015 елның 9 октябре
№ 78-ТРЗ